**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БОЛЬШЕЕЛГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422640, с. Большая Елга,
ул.Октябрьская, дом 25

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОЛЫ ЕЛГА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Октябрь урамы, 25 йорт,
Олы Елга авылы,
Балык Бистәсе районы, ТР, 422640

Тел.: (84361) 25265, факс: (84361) 25265, e-mail:Belg.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2019елның 11 октябре** **Олы Елга ав.** **№ 61**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 12 мартындагы “Үзидарәлек хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында” 6 номерлы карары белән расланган васыятьнамәләр һәм ышанычнамәләрне таныклау буенча үзидарәлек хезмәте күрсәтү Административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны законнар белән тәңгәллеккә китерү максатларында, 2019 елның 26 июлендәге “Россия Федерациясе нотариат турында законнар Нигезенә һәм “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 16.1 маддәсенә үзгәрешләр кертү хакында” 226-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Олы Елга авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, КАРАР БИРӘМ:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 12 мартындагы “Үзидарәлек хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында” 6 номерлы карары белән расланган васыятьнамәләр һәм ышанычнамәләрне

таныклау буенча үзидарәлек хезмәте күрсәтү  Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне   кертергә:

1.1) Карарның 1.5 пунктын яңа  редакциядә бәян итәргә:

“1.5.Күчемсез мөлкәт белән файдалануга ышанычнамәләрдән гайре ышанычнамәләрне таныклау буенча үзидарәлек хезмәте күрсәтү административ регламенты (Кушымта №5).”;

1.2)5 номерлы кушымтада:

а) исемне яңа редакциядә бәян итәргә:

“Күчемсез мөлкәт белән файдалануга ышанычнамәләрдән гайре ышанычнамәләрне таныклау буенча үзидарәлек хезмәте күрсәтү административ регламенты”;

б) 1.1, 3.3.1. пунктларында “васыятьнамәләрне таныклау буенча һәм” сүзләрен төшереп калдырырга;

в)  1.4 пунктның икенче абзацын төшереп калдырырга;

г) 2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.1. Үзидарәлек хезмәтенең исеме | Күчемсез мөлкәт белән файдалануга ышанычнамәләрдән гайре ышанычнамәне таныклау | “Россия Федерациясенең нотариат турында законнар Нигезе” (РФ ЮС тарафыннан расланган 11.02.1993 №4462-1) |

д)  2.3 һәм 2.4  пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.3.Үзидарәлек хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен тасвирлау | Күчемсез мөлкәт белән файдалануга ышанычнамәләрдән гайре ышанычнамәне таныклау буенча  нотариаль гамәлләр кылу. Күчемсез мөлкәт белән файдалануга ышанычнамәләрдән гайре ышанычнамәне таныклау буенча нотариаль гамәлләр кылуны кире кагу. | |
| 2.4.Үзидарәлек хезмәте күрсәтү срогы | Күчемсез мөлкәт белән файдалануга ышанычнамәләрдән гайре ышанычнамәләрне таныклау мөрәҗәгать иткән мизгелдән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла | |

е) 3.4.1. пунктының тугызынчы абзацында “васыятьнамәләрне нотариаль таныклау һәм” сүзләрен төшереп калдырырга.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы  Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы,Олы Елга авылы , Октябрь урамы, 25 нче йорт; Казаклар авылы, Үзәк урам, 9 нчы йорт;  Саескан Тавы авылы, Үзәк урам, 16А йорт;  Кама поселогы, Курортная-2 урамы, 23 йорт һәм  Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының  http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында  һәм  http://pravo.tatarstan.ru.веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “ Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Елга авыл җирлеге башлыгы Ф. Ә. Садриев